«Раслыйм»
Татарстан Республикасы
Чистай муниципаль районы
«Чистай шәһәре» муниципаль берәмлегенең
җирдән файдалану һәм төзелеш
кагыйдәләре буенча комиссия рәисе

_______________________Ф.М. Садыйков

№ 12
2022 елның 10 ноябре

Территорияләрне планлаштыру һәм межанлау проектлары һәм «Чистай шәһәре»муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү проекты буенча ачык тыңлаулар нәтиҗәләре турында

**БӘЯЛӘМӘ**

Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының «Чистай шәһәре» муниципаль берәмлеге башлыгының «Территорияләрне межалау проекты буенча ачык тыңлаулар билгеләү турында» 2022 елның 13 октябрендәге 22 номерлы, «Территорияне планлаштыру проекты буенча ачык тыңлаулар билгеләү турында» 2022 елның 13 октябрендәге 23 номерлы, «Ачык тыңлауларны билгеләү турында» 2022 елның 25 октябрендәге 24 номерлы карарлары белән билгеләнгән ачык тыңлулар 2022 елның 10 ноябрендә 10 сәгатьтә 00 минутта Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының конференц залында түбәндәге адрес буенча узды: Татарстан Республикасы, Чистай муниципаль районы, Чистай шәһәре, Бебель урамы, 129 нчы йорт.

Территорияләрне планлаштыру һәм межанлау проектлары һәм «Чистай шәһәре» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү проекты буенча 2022 елның 10 ноябрендәге 12 номерлы ачык тыңлаулар үткәрү беркетмәсе.

**Ачык тыңлаулар предметы:**

1. «Чистай БТИ» ҖЧҖ мөрәҗәгате буенча Татарстан Республикасы, Чистай шәһәре Вахитов, Шәмсетдинов, Чернышевский, Җиңүнең 40 еллыгы урамнары чикләрендәге территорияне межалау проектын карау турында.
2. «Геопроект» ҖЧҖ мөрәҗәгате буенча Чистай шәһәренең төньяк-көнчыгыш районы территориясен планлаштыру проектын карау турында.
3. «Геопроект» ҖЧҖ мөрәҗәгате буенча Чистай муниципаль районы Чистай шәһәр Советының «Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы «Чистай шәһәре» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында» карары проектын карау турында.

**Карар иттеләр:**

1. «Чистай шәһәре» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү проекты буенча ачык тыңлауларны узган дип санарга.

2. Татарстан Республикасы, Чистай шәһәре Вахитов, Шәмсетдинов, Чернышевский, Җиңүнең 40 еллыгы урамнары чикләрендәге территорияне межалау проектын хупларга.

3. Чистай шәһәренең төньяк-көнчыгыш районы территориясен планлаштыру проектын хупларга.

4. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы «Чистай шәһәре» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәреш кертү турындагы проектны хупларга һәм раслау өчен «Чистай шәһәре» муниципаль берәмлеге Советына җибәрергә.

5. Әлеге бәяләмәне ТР хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм ТР Чистай муниципаль районының рәсми сайтында (chistopol.tatarstan.ru) урнаштырырга.

Комиссия секретаре: ____________________Хөснетдинов А.Н.